**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**№ 968** **“15” декабрь 2023 ел**

2024 елга халык өчен торак
хезмәтләре күрсәтүгә тарифлар турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 маддәсенә ярашлы рәвештә, Спас муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булу чорына кушымталар буенча календарь бүленеше белән раслансын:

-күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннары милекчеләренең торак урыннарын арендалаучылар өчен торак урынна-рын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме, 1 нче кушымта нигезендә;

- муниципаль торак фондының торак урыныннан файдаланган өчен түләү күләме (аренда өчен түләү) 2 нче кушымта нигезендә;

2. Торак милекчеләре ширкәтләренә, идарәче компанияләргә, торакны тоту һәм ремонтлау өчен түләүләрне әлеге карар белән билгеләнгәннән түбәнрәк кабул итмәскә киңәш итәргә.

3. Әлеге карарны район газетасында “Новая жизнь”, “Яна Тормыш” бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләнергә.

Спас муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе: В.А. Осокин

Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның
15 декабрендәге 968 номерлы карарына
1 нче кушымта

**КҮПФАТИРЛЫ ЙОРТ БЕЛӘН ИДАРӘ ИТҮ ЫСУЛЫН САЙЛАУ ТУРЫНДА КАРАР КАБУЛ ИТМӘГӘН СОЦИАЛЬ НАЕМ ШАРТНАМӘЛӘРЕ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ТОРАК ФОНДЫНЫҢ ТОРАК УРЫННАРЫН НАЕМ ШАРТНАМӘЛӘРЕ БУЕНЧА ТОРАК УРЫННАРНЫ ЯЛЛАУЧЫЛАР ӨЧЕН ТОРАК БИНАНЫ КАРАП ТОТУ ҺӘМ РЕМОНТЛАУ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ КҮЛӘМЕ**

| № п\п | Түләү исеме | Хезмәтне үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф, сум. | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2024 елның 01 гыйнварыннан 2024 елның 30 июненә кадәр | | 2024 елның 01 гыйнварыннан 2024 елның 30 июненә кадәр | |
| | | | «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге | авыл җирлекләре | «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге | авыл җирлек-ләре |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | аена торак бинаның гому-ми мәйданының кв. м. | 3-32 | 3-32 | 3-97 | 3-97 |
| 2 | Гомуми файдаланудагы йорт эчендәге урыннарны җыештыру | аена торак бинаның гому-ми мәйданының кв. м. | 1-29 | - | 1-29 | - |
| 3 | Йорт яны территориясен җыештыру | аена торак бинаның гому-ми мәйданының кв. м. | 1-20 | - | 1-20 | - |
| 4 | Торак йортларны ремонтлау һәм йорт яны территори-ясен төзекләндерү | аена торак бинаның гому-ми мәйданының кв. м. | 3-20 | 3-20 | 3-40 | 3-40 |
| 5 | Йорт эчендәге инженерлык челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау: суүткәргеч-канализация челтәрләре | аена торак бинаның гому-ми мәйданының кв. м. | 2-40 | 2-40 | 2-40 | 2-40 |
| 6 | үзәк җылыту челтәрләре | аена торак бинаның гому-ми мәйданының кв. м. | 1-65 | 1-65 | 1-65 | 1-65 |
| 7 | газ белән тәэмин итү челтәрләре | аена торак бинаның гому-ми мәйданының кв. м. | 0-30 | 0-30 | 0-30 | 0-30 |
| 8 | электр белән тәэмин итү челтәрләре | аена торак бинаның гому-ми мәйданының кв. м. | 1-23 | 1-23 | 1-23 | 1-23 |
| 9 | Вентиляция каналларына техник хезмәт күрсәтү | аена торак бинаның гому-ми мәйданының кв. м. | 0-32 | 0-32 | 0-34 | 0-34 |
| 10 | Төтенлекләргә техник хезмәт күрсәтү | аена торак бинаның гому-ми мәйданының кв. м. | 0-42 | 0-42 | 0-45 | 0-45 |

Спас муниципаль районы Башкарма комитетының
2023 елның 15 декабрендәге 968 номерлы
карарына 2 нче кушымта.

**МУНИЦИПАЛЬ ТОРАК ФОНДЫНЫҢ ТОРАК УРЫНЫННАН ФАЙДАЛАНГАН ӨЧЕН ТҮЛӘҮ КҮЛӘМЕ (АРЕНДА ӨЧЕН ТҮЛӘҮ)**

| **Түләү исеме** | **Хезмәтне үлчәү берәмлеге** | **Календарь белән бүленгән үлчәү берәмлеге өчен түләү күләме (рубльдә)** | |
|---|---|---|---|
| | | **01.01.2024 елдан 30.06.2024 елга кадәр** | **01.07.2024 елдан 31.12.2024 елга кадәр** |
| 1 | 2 | | |
| муниципаль торак фондының торак урынынан файдаланган өчен түләү күләме (аренда өчен түләү) | аена торак бинаның гомуми мәйданының кв. м. | 6-95 | 6-95 |